

Ельник районы Акчеево авыл администрациясенə кергəн Чvриле (Чурино) авылы халкы бергəлəп Корбан бəйрəмен табигать кочагында vткəрделəр.
Корбан бəйрəме һəрберебезнен кvнелленə иман нуры кертə! Моселман халкынын ел буена котеп алган кадерле бəйрəме - Корбан гаете.
Иртəн таннан кечкенə генə авылыбызнын яше-карты, чистарынып, матур киемнəрен киеп һəм Мəскəv, Санкт-Петербургтан туган йортларына кайткан якташларыбыз белəн, зур бер гаилə булып, башта мəчеттə бəйрəмне башлап дога кылдылар.      Имам Ринат Руфят улы Кутуев дога кылды, халыкка вəгазь сойлəде, аннары корбанны бугазап дога кылды.
Гарəп теленнəн “корбан” сvзе “нəрсəгə дə булса якынаю” дип тəржемə ителə. Бу очракта Аллаһы Тəгалə ризалыгына якынаюны анлата. Корбан ите оч тигез олешкə бvленə. Бер олеше корбан чалучыга ашарга кала, икенче олеше ярлы һəм мохтажларга таратыла, оченче олеше белəн бəйрəм табыны əзерлəп туганнарны һəм дусларны сыйлыйлар.
Шокер, Чvриле авылдашларыбыз арасында да бар мондый кин кvнелле затлар: ул – бvген Мəскəvдə яшəvче Ринат Халим улы Мещерев, корбанлык бирvче. Шул корбаннын бер олешен килə алмаган Чvриле картларына тараттылар, ə икенче олешенннəн казанда шулпа пешереп бергəлəп сыйландык.
Бvгенге кондə доньяда барган вакыйгаларны кvз унында тотып, ин əввəл авыл халкыбыз бер-берсенə ил-конебезгə тотрыклылык, иминлек телəде. Доньяда татулыктан да кадерле нəрсə юк һəм мона һəр-кемнен тормышка анлы караш кvрсəтvе, топле гамəллəре аша гына ирешv момкинлеген əйттелəр. Аннары Аллаһы Тəгалə безгə бəхет, сəламəтлек, гаилəлəребезгə, илебезгə тынычлык, иминлек, муллык һəм хəерле бəракəтен индерсен дигəн телəклəрне телəделəр.

**Альфия КУТУЕВА**